Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Сабай торак пунктында

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

08.11.2019 № 1

06.10.2003 елның № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 25.10.2019 елның 27 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Сабай торак пункты территориясендә халык җыены карар итте:

1. 2020 нче елда Саба муниципаль районының Тимершык авыл җирлегенең Сабай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшне башкаруга юнәлдерергә:

- Сабай торак пунктында чишмә ремонты.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/timershik адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Тимершык авыл җирлеге башлыгы

А.Х. Хаҗиев